ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН, МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ, ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның "19" декабре № 92

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль берәмлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 25 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Уставының 19 статьясына нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны 2026 елның 16 гыйнварында 16.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

3.Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 19 гыйнварыннан да соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга.http://pravo.tatarstan.ru

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

М.Н. Гирфанов

Глухова О.С.
5-28-28